| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**СОВЕТ КАВЗИЯКОВСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ**<br>**ҖИРЛЕГЕ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.06.2025 ел №8

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3,7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының бишенче чакырылыш Кәүҗияк авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Сарман» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Кәүҗияк авыл җирлеге
Советы Рәисе Ф. Ә. Хөснетдинов